РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Ленина, 17Б
тел. (8262) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатышавылы, Ленин урамы, 17Б йорт
тел. (8262) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
18.03.2026

КАРАР
№5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 23.10.2024 елның 20 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 №425-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 23.10.2024 №20 карарына түбәндәге үзгәреш кертергә

1.1. 2 пунктның 6 пунктчасында «, төзелеп бетмәгән объектлардан тыш аларның проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булып тора» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл жирлеге рәсми сайтында ttp://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сатыш авыл жирлеге башлыгы: Ф.Ф.Шафигуллин